# Татар милли ризыклары тарихы

Татар халкы үз милли ашларына бик бай, һәм бөтен дөньяга үз ризыклары белән мәшһүр.

Азыкны казанда пешергәннәр, йөздереп кыздырганнар һәм мичтә пешергәннәр. Мичтә бигрәк тә ипи пешергәннәр. Иписез көндәлек аш та, бәйрәм табыны да узмый, ул изге азык.




- **Барлык ашамлыкларны түбәндәге төрләргә бүләргә мөмкин:**
- **шулпалы кайнар ашлар;**
- **икенче итеп бирелә торган ашлар;**
- **камыр ашлары;**
- **чәй янына бирелә торган татлы ашамлыклар.**

- Күбрәк пешкән ит кулланганнар. Итне ашка  зур-зур кисәкләр итеп салганнар, ашар алдыннан гына тураганнар.
- Итне җәй һәм яз көннәрендә куллану өчен тозлап һәм каклап куйганнар.

- Азыкны мичтә пешер өчен чуен һәм чүлмәкләр тотканнар.
- Чуенда - бәрәңге борчаклы аш, боткалар пешергәннәр.




**Татар халкында пилмән - бәйрәм көннәрендә, я кунак чакырганда әзерләнә, аны һәрвакыт шулпа белән бирәләр.**



**Кунак чакырганда, бигрәк тә шәһәр кешеләре, пылау пешерәләр.**



**Татар халкы йомырканы камыр ашларында күп куллана.  Аны пешереп тә, кыздырып та ашыйлар.**





**Өчпочмак та традицион татар ашамлыгы, аның эченә элек ит белән суган гына салганнар, соңрак турап бәрәңге дә куша башлаганнар.**



**Камырдан пешергән ашамлыклар арасында пәрәмәч зур урын алып тора**





**Кыстыбый- гади ашамлыклардан санала. Юка җәймә эченә тары боткасы салып ясаганнар. 19 гасырда кыстыбый эченә бәрәңге боламыгы сала башлаганнар.**



Гөбәдия-бик үзәнчәлекле ашамлык, аны күбрәк шәһәр халкы әзерли.

**Татар халкы элек**

**электән чәйне яратып**

**эчә. Татлы**

**камырлардан чәй**

**янына куела торган -**

**- катлама, кош теле.**





# Чәкчәк



**Милләтебез горурлыгы, табынның күрке – чәкчәк. Ул һәр туй мәҗлесендә була.**